КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 21 декабрь г.Казань № 1387

«Рубин» футбол клубы» автоном коммерциягә карамаган оешмасын төзү турында

«Коммерциягә карамаган оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасында физик культура һәм спортны үстерү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының «Рубин» футбол клубы» автоном коммерциягә карамаган оешмасын (алга таба – Автоном оешма) төзү турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына:

Автоном оешманы гамәлгә куючының функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашырырга;

30 көн эчендә Автоном оешма уставын расларга;

Автоном оешманы дәүләт теркәвенә алуны законнар белән билгеләнгән тәртиптә тәэмин итәргә;

30 көн эчендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына Автоном оешманың идарә составы буенча тәкъдимнәр кертергә;

Автоном оешма төзүгә бәйле башка чараларны үткәрергә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин